ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2023 г.Мензелинск № 128

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы №102 карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2022елның 31 мартындагы №102 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.1 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлек гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантларын, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтергә тиеш».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М. Р. Кәримов